КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 23 сентябрь г.Казань № 859

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының максатларын һәм бурычларын ачык формалаштыру һәм аларның үтәлешенә җәмәгать контроле турында» 2019 ел, 25 октябрь, 956 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының максатларын һәм бурычларын ачык формалаштыру һәм аларның үтәлешенә җәмәгать контроле турында» 2019 ел, 25 октябрь, 956 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

вәкаләтле органнарның максатларын һәм бурычларын ачык формалаштыруда һәм аларның үтәлешенә җәмәгать контролендә катнашу өчен экспертларны сайлап алу тәртибен һәм критерийларын раслауны;

ел саен, 10 сентябрьгә кадәр, вәкаләтле органнарның тәкъдимнәрен исәпкә алып, һәр вәкаләтле орган өчен экспертлар төркемнәре составларын формалаштыруны һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы яки Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы советы утырышларында раслауны.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының максатларын һәм бурычларын ачык формалаштыру һәм аларның үтәлешенә җәмәгать контроле тәртибендә:

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Вәкаләтле органның максатларын һәм бурычларын ачык формалаштыру өчен тәкъдимнәр җыю

2.1. Экспертлар кандидатуралары турындагы тәкъдимнәр вәкаләтле орган тарафыннан, агымдагы елның 20 августыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы адресына җибәрелә.

2.2. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, вәкаләтле органның экспертлар кандидатуралары турындагы тәкъдимнәрен исәпкә алып, аның тарафыннанн билгеләнгән тәртип һәм сайлап алу критерийлары нигезендә вәкаләтле органның максатларын һәм бурычларын ачык формалаштыруда һәм аларның үтәлешенә җәмәгать контролендә катнашу өчен кимендә җиде һәм иң күбе 15 кешедән торган экспертлар төркеме (алга таба – экспертлар төркеме) составын раслый.

2.3. Вәкаләтле орган:

максатларны һәм бурычларны ачык формалаштыруны башлап җибәрү турында игълан иткән көннән биш календарь көн эчендә экспертлар төркемен вәкаләтле органның максатларын һәм бурычларын ачык формалаштыру өчен кирәкле актуаль аналитик материаллар һәм статистика мәгълүматы белән тәэмин итә;

максатларны һәм бурычларны ачык формалаштыруны башлап җибәрү турында игълан иткән көннән 14 календарь көн эчендә экспертлар төркеменнән чираттагы елга вәкаләтле органның максатлары һәм бурычлары турында бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча тәкъдимнәр җыюны һәм анализлауны гамәлгә ашыра;

чираттагы елга вәкаләтле органның максатлары һәм бурычлары турындагы тәкъдимнәрне җыю тәмамланган көннән 10 календарь көн эчендә экспертлар төркеме, вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы вәкилләре катнашында тәкъдимнәр турында фикер алышу буенча эксперт сессиясен үткәрә.

2.4. Эксперт сессиясен үткәргән көннән соң 14 календарь көн эчендә тәкъдим ителгән тәкъдимнәр экспертлар төркеме катнашында иҗтимагый совет утырышында карап тикшерелә, аның йомгаклары буенча иҗтимагый совет карары белән чираттагы елга вәкаләтле органның максатлары һәм бурычлары исемлеге төзелә, кагыйдә буларак, ул халыктан киләсе сораштыруны үткәрү өчен кимендә 15 һәм иң күбе 20 позициядән тора.

Сораштыру өчен формалаштырылган исемлектә максатлар һәм бурычлар кыска һәм ачык, төгәл булырга һәм аларга ирешүнең индикатив күрсәткечләрен үз эченә алырга тиеш.»;

3 бүлекнең исемендә «вәкаләтле органнарның» сүзләрен «вәкаләтле органның» сүзләренә алыштырырга;

3.1 нче пунктында «вәкаләтле органнарның» сүзләрен «вәкаләтле органның» сүзләренә алыштырырга;

3.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Техник оператор:

«Халыкны сораштырулар» бүлегендә, бу бүлекнең гамәлдәге функциональ мөмкинлекләрен исәпкә алып, бу Тәртипнең 3.1 нче пункты нигезендә барлык вәкаләтле органнардан мәгълүмат алган көннән соң биш календарь көннән дә соңга калмыйча, вәкаләтле органнарның максатларын һәм бурычларын билгеләү буенча сораштыруларны бер үк вакытта урнаштыруны тәэмин итә;

кулланучыларга басылып чыккан сораштыру тасвирламасы белән бер гомуми тарату ярдәмендә сораштырулар оештыру турында хәбәр итүне гамәлгә ашыра.»;

3.8 нче пунктта «вәкаләтле органнар» сүзләрен «вәкаләтле орган» сүзләренә алыштырырга;

4 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Вәкаләтле органның ачык формалаштырылган максатларының һәм бурычларының йомгаклау исемлеген раслау һәм аңа төзәтмәләр кертү»;

4.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Иҗтимагый совет карары буенча утырышка вәкаләтле орган вәкилләре, экспертлар төркеме, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре һәм гражданнар чакырыла.»;

4.7 нче пунктта «вәкаләтле органнарның» сүзләрен «вәкаләтле органның» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 4.9 – 4.13 нче пунктлар өстәргә:

«4.9. Россия Федерациясе яки Татарстан Республикасы территориясендә җиңеп булмый торган көч вакыйгалары барлыкка килгән яки агымдагы елга аерым ачык формалаштырылган максатларны һәм бурычларны үтәү мөмкинлеген чикли торган куркыныч йогышлы авырулар таралуга юл куймауга юнәлдерелгән чаралар кертелгән очракта, вәкаләтле орган мондый күрсәткечләр мәгънәләренә төзәтмәләр кертү өлешендә агымдагы елга ачык формалаштырылган максатлар һәм бурычлар исемлегенә үзгәрешләр кертергә хокуклы.

4.10. Вәкаләтле органның агымдагы елга ачык формалаштырылган максатлары һәм бурычлары күрсәткечләре мәгънәләренә үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәре, аңа мондый үзгәрешләр кертүгә мотивлаштырылган нигезләмәләрне теркәп, һәм боерык проекты вәкаләтле орган тарафыннан Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына карап тикшерүгә җибәрелә.

4.11. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы агымдагы елга ачык формалаштырылган максатлар һәм бурычлар күрсәткечләре мәгънәләренә үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр кергән көннән 14 календарь көн эчендә экспертлар төркеме тарафыннан тәкъдим ителгән тәкъдимнәрне карап тикшерү йомгаклары буенча бәяләмә әзерләүне тәэмин итә. Бәяләмә иҗтимагый совет рәисенә җибәрелә.

4.12. Эксперт бәяләмәсе кергән көннән 10 календарь көн эчендә иҗтимагый совет утырышы үткәрелә, анда иҗтимагый совет гади күпчелек тавыш белән ачык формалаштырылган максатлар һәм бурычлар күрсәткечләре мәгънәләренә үзгәрешләр кертү буенча тәкъдим ителгән тәкъдимнәрне килештерү яки алардан баш тарту турында карар кабул итә.

4.13. Вәкаләтле орган иҗтимагый совет карары нигезендә вәкаләтле орган иҗтимагый совет утырышы үткәрелгән көннән соң 7 календарь көн эчендә вәкаләтле орган боерыгы белән расланган ачык формалаштырылган максатлар һәм бурычлар исемлегенә үзгәрешләр кертә.»;

5 бүлек исемендә «вәкаләтле органнарның» сүзләрен «вәкаләтле органның» сүзләренә алыштырырга;

5.1 нче пунктта «вәкаләтле органнар» сүзләрен «вәкаләтле орган» сүзләренә алыштырырга;

5.2 нче пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ел йомгаклары буенча 1 мартка, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән берлектә, иҗтимагый совет, максатларны һәм бурычларны ачык формалаштыруда катнашкан экспертлар төркеме әгъзалары, гражданнар, массакүләм мәгълүмат чаралары катнашында ачык формалаштырылган максатларны һәм бурычларны тормышка ашыру нәтиҗәләре буенча җәмәгатьчелек тарафыннан фикер алышу үткәрә, шулай ук әлеге җәмәгатьчелек тарафыннан фикер алышулар нәтиҗәләрен һәм бу Тәртипнең 1.5 нче пункты нигезендә ел йомгаклары буенча ачык формалаштырылган максатларны һәм бурычларны тормышка ашыру турындагы хисапларны урнаштыруны тәэмин итә.»;

5.3 нче пунктта «иҗтимагый совет һәм» сүзләреннән соң «төркем» сүзен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 5.4 нче пункт өстәргә:

«5.4. Техник оператор 15 мартка кадәр кулланучыларга хезмәт күрсәтүләр порталының шәхси кабинетларында урнаштырылган хәбәрнамәләр көйләүгечләре нигезендә хезмәт күрсәтүләр порталының «Дәүләт хакимияте башкарма органнары максатларын һәм бурычларын ачык формалаштыру һәм аларның үтәлешенә җәмәгать контроле» бүлегендә ел йомгаклары буенча ачык формалаштырылган максатларны һәм бурычларны тормышка ашыру турындагы хисапларны бастырып чыгару турында хәбәрнамәләр җибәрүне тәэмин итә.».

2. Бу карар (гамәле 2020 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла торган бу карардагы 1 нче пунктның егерме дүртенче, егерме бишенче, егерме тугызынчы – утыз дүртенче абзацларыннан тыш) 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин